КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 7 декабрь г.Казань № 1112

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кичектергесез чакырулар хезмәте – 112» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2014 ел, 13 август, 588 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кичектергесез чакырулар хезмәте – 112» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2014 ел, 13 август, 588 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 19 май, 325 нче, 2018 ел, 10 август, 652 нче, 2020 ел, 3 февраль, 70 нче, 2021 ел, 14 гыйнвар, 8 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 5 пунктның икенче абзацында «113 штат берәмлеге» сүзләрен «146 штат берәмлеге» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.
2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин